ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫң
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» марта 2025 ел № 75

Күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак урыннарын тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын, 2025 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районында торак урынарын тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар

Россия Федерациясе Торак кодексының 158 статьясындагы 4 өлеше, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2018 елның 6 апрелендәге 213/пр номерлы «Күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак бинаны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү буенча методик киңәшләрне раслау, торак урынын карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү, шулай ук мондый түләү күләмен үзгәртүнең чик индексларын билгеләү тәртибен билгеләү турында», Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 15 ноябрендәге 3287-р номерлы «Россия Федерациясе субъектлары буенча уртача 2025 елга коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен һәм күрсәтелгән индекслар күләменнән 2025-2028 елларга аерым муниципаль берәмлекләр буенча иң чик мөмкин булган тайпылышларны үзгәртү индексларын раслау турында» күрсәтмәсе, «2025 елга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләүнең күләме үзгәртүнең иң чик (максималь) индекслары турында» Татарстан Республикасы Рәисенең 2024 елның 14 декабрендәге 962 номерлы Указы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Күп фатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында Карар кабул итмәгән торак урыннары хуҗалары өчен торак урыннарын тоту өчен түләү күләмен үзгәртүнең чик индексын, 2025 елга Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитетында торак урыннарын тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карарны расларга:

- 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 30 июненә кадәрге чорга 0 процент күләмендә;

- 2025 елның 1 июленнән 2025 елның 31 декабренә кадәрге чорга 17,5 процент.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2025 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatartan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р. М. Латыйповка йөкләргә.

**Җитәкчесе** **И.Х. Салихов**